КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 3 июнь

г.Казань

№ 394

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан парковкалар (парковка урыннары), шул исәптән түләүле нигездә, төзү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 ноябрь, 928 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан парковкалар (парковка урыннары), шул исәптән түләүле нигездә, төзү һәм алардан файдалану тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан парковкалар (парковка урыннары), шул исәптән түләүле нигездә, төзү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 ноябрь, 928 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 7 май, 336 нчы; 2021 ел, 31 май, 409 нчы, 2023 ел, 20 ноябрь, 1493 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан парковкалар (парковка урыннары), шул исәптән түләүле нигездә, төзү һәм алардан файдалану тәртибенә,

2.8 пунктның «б» пунктчасының икенче абзацында «инвалидларның федераль реестры» сүзләрен «Социаль өлкәдә ярдәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин